ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**09.03.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 539**

2016 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан җәмәгать эшләрен оештыру турында

1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы «Җәмәгать эшләрен оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында» карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы карарын үтәү йөзеннән, эшсезлекнең икътисадый нәтиҗәләрен йомшарту һәм вакытлыча эш белән тәэмин итү һәм өстәмә хезмәт хакы рәвешендә эшләмәүче халыкка матди ярдәм күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елда иҗтимагый эшләр статусы бирелә торган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган эшчәнлек төрләре Исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә (2 нче кушымта):

2.1. Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә һәр айның 1 числосына кадәр җәмәгать эшләре күләме буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

2.2. Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән килешү буенча җәмәгать эшләрен оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә;

2.3. халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте тарафыннан җәмәгать эшләрен башкару өчен җибәрелгән гражданнарны эшкә урнаштыру һәм үз вакытында хезмәт хакы түләргә.

3. Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тәкъдим итәргә (С. В. Гататдиновага):

3.1. Зеленодольск муниципаль районы эш бирүчеләре тарафыннан игълан ителгән җәмәгать эшләренә эшсез гражданнарны оператив рәвештә җибәрүне тәэмин итәргә;

3.2. җәмәгать эшләрендә мәшгуль булган эшсез гражданнарга матди ярдәм күрсәтүне вакытында башкарырга.

4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына (А.Н.Коршуновка) әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм сайтка урнаштырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары С. В. Кадыйровка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин